СОВЕТ
ТАШКИЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Г.Тукая, д. 19, с.Ашитбаш,
Арский муниципальный район, 422039

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАШКИЧҮ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Г.Тукай урамы, 19 йорт, Ашытбаш авылы,
Арча муниципаль районы, 422039

Тел. (84366)90-2-58, факс (84366)90-3-22. E-mail: Tash.Ars@tatar.ru

**Арча муниципаль районы**
**Ташкичүавыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**« 08 » сентябрь 2026 ел** **№ 19**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичүавыл җирлеге Советының “Ташкичү авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәне раслау хакында” 2022 елның 25 октябрендәге 58 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (2023 елның 24 апрелендәге 5 номерлы үзгәрешләр белән)**

“Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Арча муниципаль районының “Ташкичү авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Ташкичү авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының “Ташкичү авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәне раслау хакында” 2022 елның 25 октябрендәге 58 номерлы карары белән расланган (2023 елның 24 апрелендәге 5 номерлы үзгәрешләр белән) Ташкичү авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 статьясындагы 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Депутатның вәкаләтләре ул сайланган көннән башлана һәм яңа чакырылыш муниципаль берәмлекнең тулы хокуклы составындагы вәкиллекле органының беренче утырышын уздырган көннән туктатыла.”.

2. Әлеге мәгълүматны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Ташкичү авыл
җирлеге башлыгы

СОВЕТ ТАШКИЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Р.Х. Хабибуллин